КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 12 декабрь г.Казань № 1115

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәгълүмат технологияләре өлкәсендәге кече эшмәкәрлек субъектларын бизнес-инкубацияләү» дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2014 ел, 26 май, 352 нче карары белән расланган «Мәгълүмат технологияләре өлкәсендәге кече эшмәкәрлек субъектларын бизнес-инкубацияләү» дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәгълүмат технологияләре өлкәсендәге кече эшмәкәрлек субъектларын бизнес-инкубацияләү» дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2014 ел, 26 май, 352 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 27 октябрь, 788 нче; 2014 ел, 29 декабрь, 1055 нче, 2015 ел, 1 апрель, 203 нче; 2015 ел, 10 октябрь, 758 нче; 2017 ел, 25 гыйнвар, 25 нче; 2018 ел, 28 август, 721 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Мәгълүмат технологияләре өлкәсендәге кече эшмәкәрлек субъектларын бизнес-инкубацияләү» дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартына, 12 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«12. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартын үтәмәгән өчен шикаятьләр бирү, теркәү һәм карау тәртибе

12.1 Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен бозган өчен шикаять (алга таба – шикаять) язма рәвештә кәгазь чыганакта йә электрон рәвештә «ИТ-парк» ДАУ тапшырыла. «ИТ-парк» ДАУ җитәкчесе кабул иткән карарларга карата шикаятьләр югарыдагы органга (ул булганда) тапшырыла йә, ул булмаса, «ИТ-парк» ДАУ җитәкчесе тарафыннан турыдан-туры карала.

1.2. Шикаять почта, күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, «ИТ-парк» ДАУ рәсми сайтыннан, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталыннан йә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең төбәк порталыннан файдаланып җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә алынырга мөмкин.

12.3. Шикаять дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турындагы законнарда билгеләнгән таләпләргә җавап бирергә тиеш.

12.4. Шикаять шикаятьләрне карау вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат тарафыннан – шикаять теркәлгән көннән унбиш эш көн эчендә, ә «ИТ-парк» ДАУ, аның вазыйфаи заты гариза бирүчедән документларны кабул итүдән йә җибәрелгән төгәлсезлекләрне һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуга карата яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылуга карата шикаять бирелгән очракта, аны теркәгән көннән биш эш көне эчендә каралырга тиеш.

12.5. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча «ИТ-парк» ДАУ дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турындагы законнар нигезендә карар кабул итә һәм аны кабул иткән көннән соң килүче эш көненнән дә соңга калмыйча гариза бирүчегә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында һәм гариза бирүче теләге буенча электрон рәвештә нигезләнгән җавап җибәрә.

12.6. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта гариза бирүчегә җавапта дәүләт хезмәтен күрсәткәндә ачыкланган бозуларны кичектергесез бетерү максатларында «ИТ-парк» ДАУ гамәлгә ашыра торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу сорала һәм дәүләт хезмәтен алу максатларында алга таба гариза бирүче башкарырга тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

12.7. Шикаятьне канәгатьләндерү кирәк түгел дип танылган очракта гариза бирүчегә җавапта кабул ителгән карар сәбәпләре турында дәлилле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

12.8. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки вазыйфаи зат җинаяте составы билгеләре билгеләнгән очракта шикаятьне карап тикшерү вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны кичектергесез рәвештә прокуратура органнарына җибәрә.

12.9. Гариза бирүче (аның законлы вәкиле) карарга һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә кылынган гамәлләргә (гамәлләр кылмауга) карата Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин